ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НОВОКИШИТСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Дружба, д. 100а, с. Новый Кишит,
Арский муниципальный район, 422034

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЯҢА КИШЕТ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Дуслык урамы, 100а йорт, Яңа Кишет авылы,
Арча муниципаль районы, 422034

Тел. (84366)55-4-42, факс (84366)55-4-42. E-mail: Nvk.Ars@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**« 18 » апрель 2019 ел** **№ 81**

Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Яңа Кишет авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә каты коммуналь калдыкларны җыю өчен контейнер мәйданчыклары урнаштыру урыннары реестрын һәм схемасын раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Җитештерү һәм куллану калдыклары турында» 1998 елның 24 июнендәге 89-ФЗ номерлы Федераль законның (2018 елның 25 декабрендәге редакциясендә) 13.4 маддәсе, «Каты коммуналь калдыкларны җыю урыннарын (мәйданчыкларын) төзекләндерү һәм аларның реестрын алып бару Кагыйдәләрен раслау турында» 2018 елның 31 августындагы 1039 нчы номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары нигезендә Татарстан Республикасы Арча мунципаль районы «Яңа Кишет авыл җирлеге» башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. 1 нче Кушымта буенча Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Яңа Кишет авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә каты коммуналь калдыкларны җыю өчен контейнер мәйданчыклары урнаштыру урыннары реестрын расларга.

2. 2 нче Кушымта буенча Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Яңа Кишет авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә каты коммуналь калдыкларны җыю өчен контейнер мәйданчыклары урнаштыру урыннары схемасын расларга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http:pravo.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы рәсми сайтында һәм ТР, Арча районы, Яңа Кишет авылы, Дуслык урамы, 100а йорты; ТР, Арча районы, Иске Кишет авылы,

Г.Сафиуллин урамы, 26а йорты; ТР, Арча районы, Кышкар авылы, Яңа урам, 125 йорт; ТР, Арча районы, Симетбаш авылы, Үзәк урам, 19а йорты адреслары буенча халык күп җыела торган урыннарда мәгълүмати стендларда бастырырга.

4. Әлеге карар аны рәсми рәвештә халыкка житкергән көннән соң үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Яңа Кишет авыл
җирлеге башлыгы Т.А.Арсланов